**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Морзалар авылында 2019 елның 16 ноябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Морзалар авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2020 елда үзара салым кертү турында" халык җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Сез

• Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карау;
• Морза авылы урамнарын яктырту.

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Морзалар авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертү белән; килешәсезме?

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча 16.11.2019 үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенгы беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 398 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 227.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 227 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Каратун авыл җирлегенең Морзалар авылында хылык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2.« Сез

• Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карау;
• Морза авылы урамнарын яктырту.

Белән килешәсезме?

соравы буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.

• Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карау;
• Морза авылы урамнарын яктырту.

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Каратун авыл җирлегенең Морзалар авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертергә.

4.Халык җыены нәтиҗәләрен информацион стендларда һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

**Авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Р. Р. Сабирҗанова**